| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 31 август г.Казань № 766

Эпидемиягә каршы чаралар үткәрү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлекләр бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү өчен бер кешегә эпидемиягә каршы чаралар үткәрүгә чыгымнарны раслау турында

«Татарстан Республикасындагы муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 ел, 16 март, ТРЗ-19 нчы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Эпидемиягә каршы чаралар үткәрү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлекләр бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү өчен бер кешегә эпидемиягә каршы чаралар үткәрүгә чыгымнарны түбәндәге күләмнәрдә расларга:

2021 елга – 16,5 сум;
2022 елга – 17,16 сум;
2023 елга – 17,85 сум.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Эпидемиягә каршы чаралар үткәрү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга Татарстан Республикасы

бюджетыннан бирелә торган субвенцияләр күләмен хисаплап чыгару өчен эпидемиягә каршы чаралар үткәрүгә чыгымнар кыйммәтен раслау турында» 2019 ел, 28 август, 729 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эпидемиягә каршы чаралар үткәрү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләр күләмен хисаплап чыгару өчен эпидемиягә каршы чаралар үткәрүгә чыгымнар кыйммәтен раслау турында» 2019 ел, 28 август, 729 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 24 декабрь, 1188 нче.

3. Бу карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин